ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге составына керүче Баскан торак пунктында 2021 елга үзара салым кертү турында

№ 6 18 нче ноябрь 2020 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең Баскан торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Баскан торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

-Баскан торак пункты Җиңү урамында вак таш түшәп юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Баскан торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

- Баскан торак пунктында Җиңү ял паркын төзекләндерү (Сабантуй мәйданы ясау,сәхнә, комиссия өчен урын, тамашачылар очен утыру урыннары ясау, спорт мәйданына баганалар утырту, яктырткычлар урнаштыру, электрүткәргеч сузу);

- Баскан торак пунктында энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, техник хезмәт күрсәтү;

-Баскан торак пункты елгасы аша җәяүлеләр күперен ремонтлау.

3. Әлеге карарны Катмыш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе И.Г.Габидуллин